**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**26.10.2022 ел** **№ 1030**

**2023 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 февралендәге 273 номерлы Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф учреждениеләрен һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга расларга:

кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарын;

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф

оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга 0,65 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эшне яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.10.2022
1030 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга НОРМАТИВ чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | первый год обучения | второй год обучения | третий и последующие годы обучения |
| Сәнгати-эстетик | авыл җирлеге | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристик-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль-икътисадый | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |